РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

Тел.: 8(84364)2-63-02, факс: 8(84364)2-63-04,e-mail:Kukmor.Kuk@tatar.ru,
www:kukmor.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

14 март, 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты турында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19 ст. 3.1 п. 3 пунктчасы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәре Советы Карары проектын хупларга һәм гавами тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 17 февралендәге 5 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Кукмара шәһәре Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Билгеләргә:

4.1. Гавами тыңлауларны үткәрү датасы – 2025 елның 7 апреле.

4.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 17.00 сәгать.

4.3. Үткәрү урыны – Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ruурнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2025 елның 14 мартындагы 3 номерлы карарына 1 нче кушымта

Кукмара шәһәре Советы карары проекты

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча нормалар һәм кагыйдәләр эшләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1042/пр номерлы РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы Боерыгы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Кукмара шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 31 октябрендәге 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә (2018 елның 05 июнендәге 11 номерлы; 2019 елның 07 августындагы 13 номерлы; 2020 елның 12 мартындагы 7 номерлы, 2022 елның 18 ноябрендәге 24 номерлы, 2024 елның 22 апрелендәге 8 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. V бүлегендәге «Этләрне йөртү мәйданчыклары» бүлекчәсе. Территорияне төзекләндерү элементларына карата таләпләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«167. Хайваннарны йөртү мәйданчыкларын су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зонасының беренче һәм икенче поясыннан читтә паркларда, урман паркларында, гомуми файдаланудагы башка территорияләрдә урнаштырырга кирәк.

Кукмара шәһәре территориясе чикләрендә хайваннарны йөртү рөхсәт ителә торган урыннар Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре администрациясе карары белән билгеләнә.

167.1 Хайваннарны йөртү мәйданчыгы территориясендәге төзекләндерү элементлары исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек, койма, махсус күнекмә җиһазлары, мәйданчыкның эт хуҗалары өчен билгеләнгән өлешендә япма (навес), эскәмияләр, урналар, фекаль салу өчен урналы бер тапкыр кулланыла торган пакетлар әрҗәсе, яктырту җиһазлары, мәгълүмати стенд.

167.2 Хайваннарны өйрәтү мәйданчыкларын төзекләндерү элементлары исемлегенә түбәндәгеләр керә: өслек, койма, махсус күнекмә җайланмалары, шул исәптән өйрәнү, күнекмә, спорт снарядлары һәм корылмалары, яңгырдан саклану өчен япма, инструкторларга ял итү өчен, җиһазларны һәм инвентарьны саклау өчен җылытылган көнкүреш бүлмәсе, эскәмияләр, урналар, фекаль салу өчен урналы бер тапкыр кулланыла торган пакетлар әрҗәсе, яктырту җиһазлары, мәгълүмати стенд.

167.3 Этләр йөртү мәйданчыклары микрорайон һәм торак районның гомуми файдаланудагы яшел үсентеләрдән азат территорияләрендә, метрополитен һәм гомумшәһәр магистральләре линияләренең техник зоналарында, көчәнеше 110 кВт тан артмаган электр тапшыру линияләре астында, су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зонасының беренче һәм икенче поясыннан читтә урнаштырылырга тиеш.

Торак билгеләнешендәге территорияләрдә урнаштырыла торган этләр йөртү мәйданчыклары 400-600 кв. м чикләрендә, башка территорияләрдә – 800 кв. м га кадәр кабул ителә, гамәлдәге төзелеш шартларында, булган территориаль мөмкинлекләрдән чыгып, мәйданчыкларның күләме киметелергә мөмкин.

Мәйданчык чигеннән торак һәм җәмәгать биналарының тәрәзәләренә кадәр ара – кимендә 25 метр, ә балалар учреждениеләре, мәктәпләр, балалар, спорт мәйданчыклары, ял мәйданчыклары участокларына кадәр кимендә 40 метр булырга тиеш.

Мәйданчыкны киртәләү, кагыйдә буларак, биеклеге кимендә 1,5 м булган җиңел металл челтәрдән эшләнә. Киртә элементлары һәм секцияләре, аның аскы кыры һәм җир арасындагы ераклык хайванга мәйданчыктан чыгып китәргә яки үзенә җәрәхәт ясарга мөмкинлек бирмәскә тиеш.

167.4 Хайваннарны йөртү һәм өйрәтү мәйданчыгын хайваннарның очлыкларын имгәтми торган, яхшы дренаж тәэмин итә торган тигез өслекле (газон, ком, ком-туфрак), шулай ук даими рәвештә җыештыру һәм яңарту өчен уңайлы каплама белән каплауны күздә тотарга кирәк.

167.5 Мәйданчыкның хайваннар хуҗалары өчен билгеләнгән өлешен каты яисә катнаш өслек (газонга батырылган плитка һ.б.) белән проектларга кирәк. Мәйданчыкка килү юлы каты өслек белән җиһазландырыла.

167.6 Хайваннарны йөртү һәм өйрәтү мәйданчыгы территориясендә мәйданчыктан файдалану кагыйдәләре урнаштырылган мәгълүмати стенд булдырырга кирәк.

168. Хайваннарны йөрү мәйданчыкларын карап тоту эшләренә түбәндәгеләр керә:

а) җәйге һәм кышкы чорда капламны карап тоту, шул исәптән: мәйданчык территориясен чистарту һәм себерү, мәйданчык территориясен юу, мәйданчык территориясенә бозлавыкка каршы хайваннар өчен куркынычсыз чаралар (мәсәлән, ком һәм вак таш бөртекләре) сибү һәм эшкәртү, агымдагы ремонт.

б) хайваннар йөртү мәйданчыгын төзекләндерү элементларын карап тоту, шул исәптән: урналарны чистарту, агымдагы ремонт.»;

1.2. 180 – 200 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 180 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «181. Йорт хайваннарын көтү җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган көтү урыннарында хуҗасы яисә аның кушуы буенча башка зат күзәтүе астында рөхсәт ителә»;
1.4. 181 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «182. Хайваннарны җирлек территориясе буйлап көтүлеккә кадәр куып илтү планы җирле үзидарә органының хокукый акты белән раслана.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2025 елның 14 мартындагы 3 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына тәкъдимнәр Кукмара шәһәре Башкарма комитетына кертелә адресы: ТР, Кукмара районы, Кукмара ш., Ленин ур., 15 й., яисә факс белән (84364) 2-63-04кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| /б № | Статья, пункт, пунктча | Кагыйдәләр проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: ТР, Кукмара районы, Кукмара ш., Ленин ур., 15 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук факс буенча (84364) 2-63-04 тапшырыла.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Кукмара шәһәре Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Мэрына тапшырыла.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев